ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $156^1$ статья өстәргә:
“$156^1$ статья. **Дендрология парклары һәм ботаника бакчалары булдыру тәртибе**

Республика әһәмиятендәге дендрология паркларын һәм ботаника бакчаларын булдыру федераль законнарда каралган таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән гамәлгә ашырыла.”;

2) 157 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Һәрбер дендрология паркының яисә ботаника бакчасының бурычлары, аны функциональ зоналарга бүлү һәм аның территориясен махсус саклау режимы үзенчәлекләре шушы дендрология паркы яисә ботаника бакчасы турындагы нигезләмәдә билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 20-ТРЗ